# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең Бикмәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «2023 елның 15» ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

02 апрель 2024 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның «02” апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең Бикмәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның «15" ноябрендәге гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700,00 (җиде йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1. Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:

- Бикмәч авылының урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- светодиод лампалар сатып алу;
- урам яктырту челтәрләрен ремонтлау.

2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

-Бикмәч авылының Беренче Май урамындагы буаны ремонтлау.

3. РФ халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

"Пушка-гаубица" һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү;

-һәйкәл территориясендә үлән чабу;

-Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемлегенең элмә такталарын, пушканың металл конструкцияләрен буяу.

4. Торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

-Беренче Май, Урман урамнары юлларын җәйге грейдировкалау хезмәтләр килешүе өчен түләү;

-Беренче Май, Урман урамнары юлларын кыш айларында кардан чистарту хезмәтләр килешүе өчен түләү;
- юл буендагы үләннәрне чабу,
- Урман урамының гравий белән капланган юллар профилен торгызу һәм түшәү буенча хезмәтләр өчен түләү,
- язгы ташу вакытында торбаларны кардан һәм боздан чистарту.

5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:

үлән чабу;
«Семык» Майданын агымдагы ремонтлау.

6. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:

- зират территориясендә үлән чабу;
- зират территориясендә агачлар һәм куакларны кисү;
- Бикмәч авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 43 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 23, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 23 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең Бикмәч торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700,00 (җиде йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү:

1. Урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау::

- Бикмәч авылының урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- светодиод лампалар сатып алу;
- урам яктырту челтәрләрен ремонтлау.

2.Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

-Бикмәч авылының Беренче Май урамындагы буаны ремонтлау.

3. РФ халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
-"Пушка-гаубица" һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү;
-һәйкәл территориясендә үлән чабу;
-Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемлегенең элмә такталарын, пушканың металл конструкцияләрен буяу.

4. Торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:
-Беренче Май, Урман урамнары юлларын җәйге грейдировкалау хезмәтләр килешүе өчен түләү;
-Беренче Май, Урман урамнары юлларын кыш айларында кардан чистарту хезмәтләр килешүе өчен түләү;
- юл буендагы үләннәрне чабу,
- Урман урамының гравий белән капланган юллар профилен торгызу һәм түшәү буенча хезмәтләр өчен түләү,
- язгы ташу вакытында торбаларны кардан һәм боздан чистарту.

5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
-үлән чабу;
-«Семык» Майданын агымдагы ремонтлау.

6. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү:
- зират территориясендә үлән чабу;
- зират территориясендә агачлар һәм куакларны кисү;
- Бикмәч авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы Г.С.Романова